КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлегенә һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, ихтыярыйлыкны, хәйриячелекне үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы эшләвен тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 август, 744 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 11 август, 791 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Коммерциягә карамаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлегенә һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, ихтыярыйлыкны, хәйриячелекне үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы коммерциягә карамаган оешмаларының мәгълүмат порталы эшләвен тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 761 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 июль, 715 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә, 1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.8. Грантлар турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июль, 703 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны

финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр субсидия алучы Килешүгә бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срокта кул куймаган булса, ул Килешү төзүдән баш тарткан дип санала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин